| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Бурметьево **КАРАР**

«19» март 2021 ел №2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның 30 мартында 13 сәгать 00 минутта Кизләү авылы, Клуб урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан Кизләү авыл мәдәният йорты бинасында Кизләү авылында яшәүче гражданнар җыенында элек расланган:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар 24.11.2020 ел, № 5;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены 24.11.2020 ел, № 6 карарына өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча җыен уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла дип билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында элегрәк расланган 24.11.2020 ел, №5 һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы торак пунктында

гражданнар җыены 24.11.2020 ел, №6 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?:

Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым тәртибендә 2021 елда җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган эшләр исемлегенә эш төрләре буенча түбәндәгеләрне өстәргә:

- халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар сатып алу (янгын гидрантларын ремонтлау һәм чистарту), Кизләү авылында (алга таба анда янгын сүндерү машинасын тоту максаты белән) гараж өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Кизләү авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар сатып алу (эшләр, хезмәтләр).

« РИЗА»　　　　　　«КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы　　　　　　Р.А. Заһертдинова